| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

1 нче декабрь 2021 ел Мөрәле ав. № 12

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Агачларны, куакларны кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны юкка чыгаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021елның 09 августындагы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Агачларны, куакларны кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны юкка чыгаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021елның 09 августындагы 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.3.1. пунктының 2 пунктчасында «агачларның, куакларның начар хәлдә булуы турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. абзац четвертый пункта 2.4.1. исключить;

1.3. 2.5.4. пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6. 1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «Башкарма комитет яисә төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.1. пунктның 6,11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3. пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның жирле үзидарә органнары, Башкарма комитет тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында «яисә гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә аеруча кирәк булган (авария хәлендәге агачларны), яшел утыртмаларны юкка чыгару кирәклеген расламау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында «авария-торгызу эшләрен башкару яисә яшел утыртмаларны юк итүгә (агачның, авария хәлендәге агачларның сынып төшү куркынычын бетерү өчен) бәйле очраклардан тыш» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «, шулай ук авария-торгызу эшләрен уздыру яисә яшел утыртмаларны юк итү өчен (агачның, авария хәлендәге агачларның сынып төшү куркынычын бетерү өчен) яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт алган очракта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3. пунктын төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5. пунктында «; авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә яшел утыртмаларны юк иткәндә муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның сынып төшү куркынычын бетерү өчен) - ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентка 2 нче кушымтада «Авария агачлары кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга, шулай ук Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге https://muralin-kaybici.tatarstan.ru/ веб.адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Мөрәле** авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Р.Р.Зиннәтуллин